**СОВЕТ АЛЬДЕРМЫШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422711, Республика Татарстан, Высокогорский район
с. Альдермыш, ул. Хабибуллина, д.25

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ӘЛДЕРМЕШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422711, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Әлдермеш авылы, Хабибуллина ур., 25

Тел./факс: +7(84365) 79-4-03, e-mail: Alder.Vsg@tatar.ru

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**
**9 декабрь 2020 ел** **№ 13**

## Әлдермеш авыл җирлеге Советының 2019 елның 12 ноябрендәге 166 нчы номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Әлдермеш авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

2003 нче елның 6 нчы октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оешмаларының гомуми принциплары турында» Федераль закон, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында, 2020 елның 31 июлендәге 268-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законның 13 статьясына үзгәреш кертү турында», 2020 елның 27 октябрендәге 347-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Әлдермеш авыл җирлеге Советы,

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Әлдермеш авыл җирлеге Советының 2019 елның 12 ноябрендәге 166 нчы номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Әлдермеш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турында Нигезләмәгә (Советның 13.02.2020 № 184 карары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 14 статьяның 3 пунктындагы 4 пунктчасын «хезмәт кенәгәсен» сүзләреннән соң «һәм (яисә) законнарда билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән хезмәт эшчәнлеге турында белешмәләр;» сүзләре белән тулыландырырга;

2) 6 статьяның 5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Җирле үзидарә органы, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппараты җитәкчесе булган муниципаль хезмәткәр, күрсәтелгән муниципаль хезмәткәрнең урынбасары мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау максатларында әлеге җирле үзидарә органының сайланулы профсоюз органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында алар тиешле вазыйфаны биләгән чорда муниципаль хезмәткәрләр мәнфәгатьләрен тәкъдим итә алмыйлар.».

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең рәсми стендларында, Интернет челтәрендәге Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ авыл җирлекләре бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Совет рәисе,
Авыл җирлеге Башлыгы Т.С.Сабиров